«БӨКЕ»СЕЗ ТОРМЫШ

Татарстанда яңа юллар ачылды

> 2



КАДЕРЛЕ ЧИМАЛ

Тик нефть дигәндә дә ул китергән табыш өскә яңгыр булып яумаячак

> 2

АКТҮБӘ ШАТЛЫГЫ

Акыллы счетчик, кояш энергиясе белән җылытылучы өйләр, чүп-чарсыз урамнар – анда гадәти хәл

> 7

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 152 (28925) | Шимбә | 15 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АЛАР – ӨЙНЕҢ ТЕРӘГЕ, АЛАР – ИЛНЕҢ ТЕРӘГЕ

16 октябрь – Әти көне

Күкләр аяз, тормыш матур булсын өчен әти кирәк! Бүген көчле затларыбыз кулларына корал тотып, Ватанны сакларга киткәндә, әти кадере тагын да артты кебек. Һәр йортта аларның исән-сау әйләнеп кайтуын көтәләр. Календарьда әтиләрнең дә үз көне бар хәзер. Россиядә икенче ел инде октябрьнең өченче якшәмбесендә Әти көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстан Иҗтимагый палатасында җәмәгать эшләрендә иң актив катнашкан әтиләрне котладылар.

Әтиләрнең дә төрлесе бар. Авыру балаларын ташлап чыгып киткәннәре, аларга алимент түләмәгәннәре, кырыслары, бар йөкне хатыннар җилкәсенә аударып, диванда телевизор карап ятканнары… Шул ук вакытта балаларын алларына утыртып сөйгәннәре, аларны җитәкләп паркларда йөргәннәре, чын гаилә токтасы булганнары да күп. Көчле әтиләрнең олы йөрәгенә, кылган гамәлләренә сокланып туя алмыйбыз. Башкалар да шундый булсын иде дип, без үрнәккә иң шәп әтиләрне генә сайладык.

Куллары мазутка буялган тракторчы әтиләрдә эш кайгысы гына түгел. Балалары яхшы белем һәм тәрбия алсын дип тырыша алар. Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче Алмаз Корбангалиев та шундыйлардан. Алмаз, эштән соң арыдым, дими, атнасына алты көн улы Әдельне Арчаның Боз сараена хоккей түгәрәгенә йөртә. Алты ел шулай. Ә бит юлы да якын түгел, бер якка 50 чакрымнан артык.

– Кичке сәгать 10да гына өйгә кайтып җитәбез. Сәгатьләр буе көтеп утыруны мәшәкатькә санамыйм. Минем кебек тагын берничә әти бар әле. Җәй көне комбайнда эшлим, буш вакыт булмый бит. Ул чакта улымны башка дусларыма ияртәм, – ди өч бала атасы Алмаз Корбангалиев. – Трай тибеп урамда йөргәнче, шунда шөгыльләнсеннәр. Россия буенча узган ярышларда җиңүләр яулыйлар. Минем Мәскәүне бер дә күргәнем юк, алар ике мәртәбә барды инде.

Алмаз әйтүенчә, ул балаларын күз карашыннан аңлый торган итеп үстерергә тырыша. Әниләре дә: «Берәр җиргә барсагыз, әтиегезгә әйтегез», – дип өйрәтә икән. «Эш кушып торам, тик торсалар, әшәкелеккә өйрәнәләр. Башларына юньсез уйлар керә күрмәсен», – ди гаилә башлыгы.

Тукай районының Иске Дөреш авылында өч баласын ялгыз үстерүче Илдар Гыйльфанов газизләре әниләре юклыгын сизмәсеннәр өчен бар көчен бирә. Иң олысына – 11, төпчегенә – 6 яшь.

– Әйбәт әти булырга тырышам. Барыбызның да сәпите бар, ел фасылына карап тормыйча, табигатькә чыгып китәбез. Су коеныргa да барабыз, шашлыгын да пешерәбез. Чаллыга аттракционнарга да алып барам. Туган көннәрен дә бергәләп бәйрәм итәбез. Камыр ризыклары да пешерәм. Балаларым коймак, пиццаны яратып ашый, – ди ул.

Илдар зарланырга ярата торганнардан түгел. Туганнар, күршеләр, дуслары да ярдәм итә икән. «Дәүләт ярдәмен сизәбез. «Путин акча»сы күчә. Пособиеләр дә алабыз. Бөтен әйбер җитеш, интегеп ятмыйбыз. Өстәмә эшләргә чыккалыйм», – ди ул. Аның фикеренчә, яхшы ул тәрбияләү әнидән тора. Хатын-кыз ирен хөрмәт итмәсә, баласы да иренең кадерен белмәячәк.

Ерак юлларга йөрүче Саба егете блогер Назыйм Галимов үзен балаларының дусты да, кумиры да дип саный. Улларының аның кебек буласы килә икән.

– Мине дә Әти көнендә гаиләдә игътибарсыз калдырмыйлар. Хөрмәт итәләр, бераз куркып та торалар, анысы да кирәк. Әниләре гел, әтиегез белсә, әтиегез күрсә, дип әйтеп тора. Алар эшләрен уйламыйча эшләми, – ди Назыйм.

Әтиләр көне алдыннан Татарстан Иҗтимагый палатасында Татарстан Әтиләр берлегенең район һәм шәһәр бүлекчәләрендәге иң яхшы әтиләрен җыйганнар иде. Аларга рәхмәт әйтеп, мактау кәгазьләре дә тапшырдылар.

– Ил авыр хәлдә булганда, чын ир-атлар Ватанны яклап чыга, – дип белдерде Иҗтимагый палата рәисе Зилә Вәлиева. Ул билгеләп үткәнчә, хәрби операциягә китүчеләр арасында балалары булган, үз ирекләре белән китүчеләр дә бар. – Мин мобилизацияләнүчеләр, шулай ук үзләре теләп китүчеләр белән дә очрашам. Минемчә, чын әтиләр яшькә карамыйча, шулай эшлиләр. Әтинең изге бурычы бар: зур гаиләдә авырлык туса, алар үз илен, гаиләсен һәм балаларын яклауга күчә. Мобилизацияләнүчеләр һәм Ватанга хезмәт итәргә әзер булучылар бар. Алар – безнең ышанычлы таянычыбыз.

ru.pinterest.com

Ахыры 2 нче биттә >

Үзебезнекеләр өчен

Татарстан Хөкүмәте мобилизацияләнүчеләрне кирәк-яраклар белән тәэмин итәчәк. «Татар-информ»га билгеле булганча, бу аларны кирәк-яраклар сатып алу мәшәкатеннән азат итү һәм чыгымнарын киметү өчен эшләнә.

Хәрби хезмәткә чакырылганнар өчен махсус перчатка, оекбаш, футболка, башлык, термокием, су үткәрми торган капчык, хәрби утыргычлар сатып алыначак. Моннан тыш, алар чүкеч, изолента, эретеп ябыштыру аппаратлары, дизель генераторлары кебек әйберләр белән дә тәэмин ителәчәк.

Мобилизацияләнгән егетләрне кирәкле әйберләр белән Россия Оборона министрлыгы тәэмин итә. Татарстан Хөкүмәте исә өстәмә ярдәм күрсәтеп, аларның әзерлеген арттырачак.

Сүз уңаеннан, өч һәм аннан күбрәк бала (16 яшькәчә) тәрбияләүчеләрне өлешчә мобилизациядән кичектерү турында карар кабул ителде. Бу хакта Дәүләт Думасының Оборона комитеты рәисе Андрей Картаполовка сылтама белән «Интерфакс» агентлыгы хәбәр итә.

Өстәмә ял

Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан ноябрь аенда өстәмә ял көтелә. Бу хакта Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәр итә.

«Татарстанда 4 ноябрь, ягъни Халыклар бердәмлеге көне һәм 6 ноябрь – Татарстан Конституциясе көне – бәйрәм буларак билгеләп үтелә», – диелгән документта. Россия Федерациясе Хезмәт кодексы буенча бәйрәм алдыннан эш көне бер сәгатькә кыскартыла. 6 ноябрь исә якшәмбегә туры килә. Шулай итеп, ноябрьдә республика халкы өч көн рәттән – 4, 5 һәм 6 ноябрьдә ял итә.

Йомырка кыйммәтләнгән

Узган атнада, ягъни 3–10 октябрь аралыгында Татарстанда кайбер азык-төлек товарларына бәяләр арту теркәлгән. Бу хакта «Татарстанстат» хәбәр итә. Әйтик, помидорга бәя 12,5 процентка – 78 сумга кадәр арткан. Бер атна элек аның уртача хакы 70 сум булган. Тавык йомыркасына да бәя 4 процентка арткан. Хәзер аның уртача хакы – 79 сум.

Шул ук вакытта арзанайган азык-төлек товарлары да бар. Әйтик, карабодайга бәя төшкән. Хәзер аның килосы – 89 сум. Алма һәм кишернең хакы да 3 процентка арзанайган. Бер кило алманың уртача бәясе хәзер – 86 сум булса, кишернеке – 25 сум.

Кредит алучылар кимегән

2022 елның сентябрендә Татарстанда барлыгы 32980 кулланучылар кредиты бирелгән. Кредит тарихлары бюросы мәгълүматларыннан күренгәнчә, бу сан август ае нәтиҗәләреннән 8,5 процентка кимрәк.

Сүз уңаеннан, сентябрьдә бирелгән кулланучылар кредитлары саны буенча Татарстан Россиянең 30 төбәге арасында җиденче урында тора. Мәскәү (61866) – беренче, Мәскәү өлкәсе (51285) – икенче, Краснодар крае (37999) – өченче урында.

Ярминкәләр дәвам итә

Татарстанда көзге ярминкәләр дәвам итә. Алар 24 декабрьгә кадәр һәр шимбә саен уздырылачак. Казан халкы республиканың 22 районыннан һәм 18 агросәнәгать оешмасыннан кайтарылган фермер продукциясен сатып ала алачак.

Ярминкәләр иртәнге 6.00дан 12.00 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк. Алар Авиатөзелеш районында Дементьев урамы, 7; Беломорская һәм Гудованцев урамнары киселешендә; Ленинград урамы, 27 адреслары буенча узачак. Вахитов районында яшәүчеләр Татарстан урамы, 53 һәм Чехов урамы, 2 адресларына рәхим итсен. Киров районында сәүдә Краснококшайская урамы, 150/2; Батыршин урамы, 20 һәм Революцион урамы, 12 йортта җәеләчәк. Яңа Савин районында ярминкәләр Ямашев проспекты, 71а һәм Лаврентьев урамы, 10 адреслары буенча, ә Идел буе районында Зорге урамы, 66 һәм Фучик урамы, 72 адресларында узачак. Совет районында яшәүчеләрне Аграр урамы, 2 («Казан» агропромпаркы) һәм Липатов урамы, 7 адреслары буенча көтәләр. «Салават Күпере» микрорайонында яшәүчеләр өчен ярминкә Осиново бистәсендә «Радужный» сәүдә үзәге парковкасында оештырылачак.

Сәламәтлек

Авырыйсы түгел

Татарстанда коронавирус белән авыручылар саны инде өченче атна кими. Бу атнада, әйтик, әлеге күрсәткеч 32 процентны тәшкил итә. Шулай да табиблар игътибарлы булырга һәм көзге чорда аеруча сакланырга киңәш итә. ОРВИ һәм грипп турында да онытырга ярамый. Республикада вакцина җитәрлек. Ковид хастаханәләрендә исә урыннар 11 процентка бушаган.

Узган тәүлектә Татарстанда 245 кешедә коронавирус барлыгы ачыкланган. Авыру гадәттә ОРВИ рәвешендә уза. Авыру йоктыручыларның 95 процентында «Омикрон» штаммы ачыкланган. Сихәтләнүчеләр күбрәк: андыйлар 587 кеше. Табиблар балаларга аерым игътибар бирә. Һәр иртә мәктәпкә кергәндә укучыларның температураларын үлчиләр, ОРВИ билгеләре булу-булмавын тикшерәләр. Әйтик, узган тәүлектә генә 142 укучыны өйләренә кайтарып җибәргәннәр. Уку елы башланганнан бирле 5873 балада авыру билгесе табылган. Чагыштыру өчен, узган елның 14 октябрендә әлеге күрсәткеч 13654 булган. Монысы да хәлләрнең кай якка баруын чамаларга мөмкинлек бирә.

Әмма белгечләр сакланырга киңәш итә. Көзге чорда бигрәк тә. Әлбәттә инде, вакцинация турында онытмаска кушалар. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков вазгыятьне чамалау өчен ике санны аерым телгә алды. Әйтик, 14 апрельдә республикада беренче мәртәбә вакцинация узган 1 млн 926 мең кеше теркәлгән. Ярты елдан соң, ягъни 14 октябрьдә аларның 525 меңе генә икенче тапкыр прививка ясаткан. Ә калганнары?

Владимир Жаворонков та, Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина да республикада вакцина җитәрлек икәнен әйтә. Быел бездә 2,4 млн чамасы кешегә грипкка каршы прививка ясарга ниятләп торалар. Даруның яртысыннан артыгы кайткан инде. Татарстанда әлегә грипп белән авыручылар теркәлмәгән. Узган ел исә беренче очрак 25 октябрьдә ачыкланган. Сүз уңаеннан, грипп һәм коронавируска каршы прививкаларның икесен дә бер көнне ясатырга мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сүзгә-сүз

tatarstan.ru

Татьяна МОСКАЛЬКОВА, Россиядә Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил:

Безгә чакырылыш чаралары дөрес үткәрелми дигән шикаятьләр күп килә. Әлбәттә, халык вазгыятьне аңлый, бурычларын үтәргә әзерләр. Ләкин төнлә повестка китерүләре күпчелекнең ачуын чыгара.

(«Парламентская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТЛӘР

«Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, 2022 елның гыйнвар – август айларында республика халкына 219,3 млрд сумлык түләүле хезмәтләр күрсәтелгән.

Түләүле хезмәтләрнең гомуми суммасы	**219,3**
Көнкүреш хезмәтләр	**33,8**

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Без «ябышкан» нефть

Белгечләр, шактый пошаманга төшеп, Россиянең акрын гына архаик, артка калган икътисадка юнәлеш алуын билгели. Сәбәбе билгеле: санкция-чикләүләр, шулар аркасында халыкара кооперациядән, хезмәт бүленешеннән читләшү, биргәк тә яңа технологияләрсез яши башлау. Чикләүләр кертелгәнче дә икътисадыбызны артык заманча дип атап булмагандыр. Чималчылыкны кәсеп итү, импортка сальну аркасында ни электроника сәнәгатен, ни авиатөзелеше күтәрә алмадык, машина төзелешенең күп юнәлешләрен зәгыйфь хәлдә тоттык.

Элек күбрәк үз ихтыярыбыз, үз теләгебез белән чималга карап ятсак, хәзер инде, кем әйтмешли, шул ук нефть белән газга дүрт куз белән мәҗбүри равештә багасы. Технологияләр сатучы, инвестицияләр белән кереп нидер төзергә, булдырырга ашкынучылар чиратка тезелмәгән. Икътисадны диверсификацияләү, ягъни күптармаклы итү хакында якын араларда гомумән дә онытып торасы. Якын киләчәктә безне тотып торучы, җан асратучы чара булып тагын да шул чимал, аерым алганда, нефть, аның кардәше – газ кала.

Тик нефть дигәндә дә ул китергән табыш әскә яңгыр булып яумаячак. Бәяләр түбәнгә мәтәлмәгән җәһәттә дә. Биредә дә сәбәпче – чикләүләр. Тәртәбезне Көнчыгыш тарафка борып, җир маен Кытай, Һиндстан кебек дәүләтләргә сата башладык. Алар, вазгыятьтән шома файдаланып, аны бездән аерым очраклада 40–45 процентка җиткән дисконт (ташлама) белән ала. Ул гынамы. Шул ук Евросоюз керткән чикләүләр 5 декабрьдән генә көченә керәсе булса да, аларның кире йогынтысы инде бүген үк күренә – «кара алтын» ташучы танкерларны иминиятләштерү туктала хәлендә. Ярты дөньяны урап, Кытайга 5 декабрьдән соң гына барып җитәсе танкерларны инде иминиятләштермиләр. Ә ул эш башкарылмыйча, бер генә судно да порттан чыкмый. Күк асты иленә, Һиндстанга таба торба сузу исә тиз башкарыла торган эш түгел. Шунысы бераз тынычландыра: дөньяда нефтькә ихтыяҗ һаман да зур, Россия аны сатмый тормаячак. Тик менә аннан килгән керем кырыкмаса-кырык төрле каршылык, шул исәптән Көнбатышның бәяләргә «түшәм» куюы аркасында сизелерлек кимеячәк. Процесс инде башланды да.

Әгәр дә кү без вакытында күптармаклы икътисад тудыра алган булсак? Ул чагында үз «кара алтын»ыбыз, ихтимал, үзебездән артмас иде. Шул ук АКШ икътисады эле дөньяда чыгарылган нефтьнең гомумән дә дүрттән берен яга. Хәтсез еллар элек үзем яшәгән шәһәрдә урнашкан нефть һәм газ табу идарәсе (НГДУ) җитәкчесеннән: «Ничек уйлыйсыз, нефть ил өчен бүләкме, әллә җәзамы?» – дип сораганым булды. Гомере буе шул тармакта эшләгән кеше, әлбәттә инде, «Җир мае ул – ил өчен бәла», – дип әйтә алмый. Башлык «бүләк» диде. Булдыклыларга ул, әлбәттә, бүләк. Татарстаныбызга да ул – бүләк. Чөнки без нефтькә генә карап яшәмибез. Үзендә күптармаклы икътисад тудырган Норвегиягә дә, халкын муллыкта яшәткән Кувейт, Берләшкән Гәрәп Әмирлекләре, Катар кебек илләргә дә нефть – бүләк. Ә Ходай бүләгенең кадерен белмәгәннәргә ул – күпчелек очракта сынау һәм дә җәза.

Бәндәләрне Ходай власть биреп, байлык биреп сыный, диләр. Күрәсең, илләрне дә ул табигый байлыклар белән сыный. Россия ул сынауны үтте дип әйтеп булмый. Совет заманнарыннан бирле без шул җир маена ябышып ятабыз. Нефтька бәя артса – сөенәбез, кимесә – көенәбез. Дөнья базарындагы бәяләргә карап яшәү – бәйлелек. Ул – бер үк вакытта тотрыксызлык та. Россия дигәндә, олы территория дә – сынау. Барысын да Хак Тәгалә: «Чын, хасиятле хуҗа була алырлармы, казылма байлыкларны акыл белән, халык рәхәтен күрерлек итеп файдаланырлармы?» – дип биргәндер. Тик... Сынауларны адәм рәтле итеп үтә алмадыкмы, күкләр җәза җибәрә. Чикләүләр, ихтимал, чираттагысыдыр.

Ә бит нефть бәяләре югары сикергән яңа гасыр башында (онытмаган булсак, даими күтәрелә килеп, бәя 2008 ел башында тарихта беренче тапкыр 100 доллар чиген узган, шул елның җәендә 147 долларга җитеп, рекорд та куйган иде) Россия өстенә нефть долларлары яңгыр булып коеп тукте. Ничә еллар буе без биредә валютаны кая куярга белми интектек. Аптырагач, Резерв фонды дигән, Милли муллык фонды (Фонд национального благосостояния) дигән олы янчыклар ясап, шунда тутырдык. Ул гынамы, долларларны АКШ корпорацияләренең кыйммәтле кәгазьләренә урнаштырдык, акцияләрен сатып алдык. Күктән ишелгән акчага доллар яңгыры сугарган туфракта зурдан кубып заводлар саласы, эре җитештерү үзәкләре булдырасы, масштаблы төзелешләргә тотынасы, бер сүз белән әйткәндә, чимал акчасын кулланып, чималчылыктан котылу, күптармаклы икътисад булдыру өстендә җиң сызганып эшлисе урында гел башка гамәлләр белән мавыктык. Шулай яши-яши бүгенгә килеп җиттек.

Без ул эшләрне ни өчен эшләмәдек соң? Диверсификация илне алдынгы дәүләтләр рәтенә чыгарудан, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүдә төп чара икәнен белү өчен икътисадчы булу да кирәкми. Ник бер дигән ул мөмкинлекне кулдан ычкындырдык без? Моны җиңел килгән нефть долларларының наркотик тәэсире, безне исертүе белән аңлатып булыр иде. Әмма җавапсызлыкта төп сәбәп – нефть бароннарының ил җитәкчелегенә булган йогынтысында, җитәкчелекнең аларны «сындыра» алмавында һәм, ихтимал, теләмәвендә булгандыр. Үзәкнең тактика, бүгенге көн белән мавыгып, стратегия, киләчәк турында уйламавында. Нефть олигархларына Россияне, аның халкының лаеклы киләчәге әллә бик кирәкме? Юк! Аларга илнең нефть энәсендә калуы мәслихәт. Биредә шау-гөр килеп станоклар, электроника, очкычлар, тулысы белән үзебезнең деталәрдән торган автомобильләр җитештерә, инновацияләр, яңа технологияләр куллана башлыйлар икән, ул кавемгә шунда ук арткы планга күчәсе булачак. Алар моңа риза түгел, аларның һаман беренче рольләрдә каласы килә...

Хәерле сәгатьтә!

КӨТЕЛГӘН ЮЛ

tatarstan.ru

Бу вакыйгаларны халык түземсезлек белән көтте. Татарстанда Казан халыкара аэропортына керә торган һәм «Салават Күпере» торак комплексыннан Горький шоссесына чыга торган юлны реконструкцияләү тәгәлләнде. Әлеге юлларны ачу тантанасында Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

«Казан» аэропортына керә торган юлны реконструкцияләү кысасында 6,4 чакрымга сузылган ике полосалы юлны дүрткә кадәр арттырганнар. Шулай ук участокта биш ясалма корылма ясаганнар. Машиналар борылганда куркынычсыз булсын өчен, 244 метрлы борылыш эстакадасы да эшләнгән. Болардан тыш, Зур һәм Кече Кабан авылларында яшәүчеләргә уңайлы булсын өчен ике җир асты җәяүлеләр кичүе төзегәннәр. Җәяүлеләр юлы белән дүрт автобус павильоны да урнаштырылган.

– Бүген чыннан да безнең республика өчен зур вакыйга. «Казан Экспо»ны ясагач, аэропортка бара торган юл тыгызланды, монда һәрвакыт «бөке»ләр барлыкка килә башлады. Без бүген бу трассаны ачып, рәхәтләнеп йөрибез, – диде әлеге үзгәрешләрне бәяләп Рөстәм Миңнеханов.

Кичә шулай ук «Салават Күпере» торак комплексын һәм Осиново бистәсен Горький шоссесы белән тоташтыручы юлны да рәсми төстә ачтылар. Моңа кадәр Залесный урамы борылышыннан алып торак комплексына кадәрге юл ике полосалы булганлыктан, машиналарга озаклап «бөке»ләрдә утырырга туры килә иде. Хәзер алар дүрт полосалы юлдан җилдерә алачак. Әлеге үзгәрешләр нәтиҗәсендә техника агымының уртача тизлеге якынча 28 процентка артыр, дип фаразлыйлар. Билгеле булганча, моның өчен 24 йортны сүткәннәр һәм юлга якын булган башка йортларга тавышлар комачауламасын өчен махсус экраннар урнаштырганнар.

Президент әйтүенчә, юлны киңәйтү – биредә яшәүче халык өчен көтеп алынган вакыйга.

– Бу юл шулай ук бик кирәкле. Кешеләр рәхмәтле булыр, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Татарстанда һәм илдә бервакытта да шулкадәрле юл төзелгәне булмады: М12 дә, М7 дә һәм Шәле – Баулы юлы да. Болар – юл хезмәткәрләренең тырышлыгы нәтиҗәсе. Алар ил һәм төбәк җитәкчелеге куйган бурычларны төгәл үти. Иң мөһиме – юллар үсеше тормыш сыйфатын яхшырта.

Марат Хөснуллин билгеләп узганча, озынлыгы зур булмаса да, барлык юллар да территорияне алга таба үстерер өчен мөһим роль уйный.

– Аэропортка керә торган юл бу зонаны үстерер өчен мөһим. Монда күргәзмә үзәге дә, торак йортлар да, аэропорт та. Кайчандыр Казан аэропорты миллионнан да азрак кешене кабул итә иде, ә узган ел 3,8 млн булды. Быел да шулай ук. Һәм, әлбәттә, алга таба аэропорт бу юлдан башка эшли дә, үсә дә алмас иде, – диде вице-премьер.

Моннан тыш, Марат Хөснуллин «Казан Экспо»дагы «Юл – 2022» халыкара күргәзмәсен карады. Биредә юллар төзи торган техникалар тәкъдим ителгән иде.

Көннең икенче яртысында исә федераль җитәкче җитәкчелегендә илнең автоюл челтәрләре үсеше буенча киңәшмә узды. Монда сүз башлыча «Көнбатыш – Көнчыгыш» халыкара транспорт коридорын үстерү турында барды.

Моннан тыш, Марат Хөснуллин «Иң яхшы муниципаль практика» федераль конкурс комиссиясе утырышын үткәрде. Анда Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Исегезгә төшерәбез: әлеге бәйге 2017 елдан бирле үткәрелә. Быел җиңүчеләргә 900 млн сум акча бирелачәк.

Форум кысасында Рөстәм Миңнеханов Бурятия Республикасы башлыгы Алексей Цыденов белән күреште. Ике як төбәкләр арасындагы хезмәттәшлекне үстерү, товар һәм хезмәтләр белән үзара тәэмин итү күләмен арттыру, гуманитар өлкәдә үзара хезмәттәшлекне нығыту турында фикер алыштылар. Шулай ук Рөстәм Миңнеханов Алексей Цыденовка ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан медаль тапшырды.

Сүз уңаеннан, «Казан Экспо»да «Россия Федерациясенең юллар хуҗалыгын тотрыклы үстерү» пленар утырышы, «Транспорт» юнәлеше буенча Россия Федерациясе Дәүләт Советы комиссиясе утырышы да узды.

Алар – өйнең терәге, алар – илнең терәге

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанда Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец чыгышында: «Мин гаилә җепләре өзелгән шактый гаиләләрне беләм», – диде. Аның әйтүенчә, Әтиләр берлеге әлеге хәлне үзгәртү өчен үз өлешен кертә.

– Үз балаларына ярдәм итәргә атлыгып торучы әтиләрнең күп булуы әйбәт. Берничә ел элек мәктәпләрдә ата-аналар җыелышларында әтиләр берничә генә була иде. Хәзер алар күбрәк күренә башлады, – ди вәкаләтле вәкил. – Кызганыч, гаиләләрнең яртысы таркала. Шул сәбәпле балалар әтисез үсә. Үзләре исән булганда, мондый хәлгә юл куймаска кирәк. Безнең һәрберебез әтиләрнең дәрәҗәсен күтәрү турында уйларга тиеш. Әти ул – гаилә терәге.

Татарстан Әтиләр берлеге рәисе Гадел Заһретдинов әйтүенчә, Әтиләр берлекләре барлык район һәм шәһәрләрдә диярлек бар.

– Авыру, ятим, тормышта авыр хәлләрдә калган, күпбалалы гаиләләргә, хәзерге вакытта хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренә ярдәм итәбез. Ул-кызлары бакчага йөргәннәр күбрәк – бакчага, мәктәпкә йөргәннәре мәктәпкә ярдәм итә. Ел дәвамында төрле чаралар уздырабыз. «Кар кызы. Кыш бабай. Кунак» дигән чарага әзерләнәбез. Әтиләр Яңа ел чыршысына бара алмаган аз керемле, авыру балаларга бүләкләр тарата, – ди Гадел Заһретдинов.

«Әтиләр берлеген нинди проблемалар борчый?» – дип сорагач: «Бу сүзне яратмыйм. Бездә проблема юк, максатлар гына. Хәл ителмәслек бер генә мәсьәлә дә юк. Бөтен проектлар – балалар өчен», – диде Гадел Заһретдинов.

Кукмара Әтиләр берлеге рәисе, Зур Кукмара мәктәбе директоры Илфат Тимергалиевның да фикерен сораштык.

– Ниндидер чара уздырып, балаларны ярышттырып кына, эш үткәрдем, дип булмый. Көн саен аңгәмәләр уздырабыз, балалар, әти-әниләр белән сөйләшәбез. Барысы да шушы хезмәткә керә. Балалар тәрбиясе булсын, унышка ирешсен өчен, әтиләрнең балаларга карашы үзгәрү кирәк, чөнки төрле гаиләләр бар. Үрнәкне яхшы гаиләләрдән алу кирәк, – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә ФАЗЛЫЕВАдан Әти көне уңаеннан бәйрәм котлавы килеп иреште. Анда болай диелгән:

– Безнең илдә элек-электән ир-ат үз гаиләсен яклаучы, туендыручы, улары һәм кызлары өчен үрнәк булган. Әтиләрдән балалар хезмәт сөяргә, якыннары кайгыртырга, үз гамәлләре өчен җавап тотарга, көчсезне сакларга, мөһим карарлар кабул итәргә өйрәнә. Нәкъ менә әтиләр батырлык һәм намуслылык үрнәге булып тора.

Сезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек һәм иминлек телим. Сезнең өйдә һәрвакыт татулык, үзара аңлашу һәм мәхәббәт яшәсен.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе **Валиева** Зилә Рәхимҗан кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Удмурт Ташлысы авыл җирлеге башлыгы **Дегтярев** Николай Сөләйман улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Охтин-Ойл» ябык акционер җәмгыятенең әйдәүче геологы (Ленинградская өлкәсе) **Фәттехдинова** Роза Ахунҗан кызына **«Татарстан Республикасының атказанган геологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

СЕЗ БЕЗГӘ ҮРНӘК

Бәйрәм уңаеннан

Республиканың өлкәннәренә сокланып туеп булмый. Алар һәр эштә актив. Январьнда басып кына торсаң да, үзеңдә яшәү көче артканны сизәсең. Төс-кыяфәтләренә карасаң, бер дә үз яшьләрен бирмисең. Өлкәннәр соңгы елларда, лаеклы ялга чыгу дип түгел, яшьлеккә кайту дип сөйлиләр.

Өлкәннәр ялгыз түгел. Аларны һәр районда, авылларда ветеран оешмалары бергә җыеп тора. Бу хакта Казанның Филармония концертлар залында республика ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы үзенең 35 еллык юбилеен бәйрәм иткәндә сөйләделәр. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә республиканың ветераннар хәрәкәтенә югары бәя бирде.

– Бу оешма республика язмышына, Татарстан һәм Россия халкының иң яхшы традицияләренә битараф булмаган өлкән буын кешеләрен берләштерә, – диде ул. – Шуңа күрә без сезнең эшегезне югары бәялибез һәм сезне күпмиллетле халкыбызның җаны дип саныйбыз. Сезнең хезмәт белән республикабызның күәтле икътисады төзелде, сезнең кулларыгыз аның социаль-икътисади үсешенә нигез салды. Фидакарь хезмәтегез, бәялап бетергесез тәҗрибәгез һәм республика тормышында актив катнашуыгыз өчен рәхмәт сезгә.

Бүген республикада 900 меңнән артык өлкән кеше яши. Районнарда һәм шәһәрләрдә 55 җирле совет төзелгән, анарда 45 мең активист исәпләнә. Фәрит Мөхәммәтшин да, соңгы елларда ветераннарның республика советы абруйлы иҗтимагый оешмаларның берсенә әверелде, ди.

– Үсеп килүче буынга рухи-әхлакый кыйммәтләрне, гореф-гадәтләрне, телләрне һәм мәдәниятләрне тапшыруда ветераннарның роле бәяләп бетергесез. Бу эштә бигрәк тә «Балкыш» – «Сияние» фестивальләре роле зур, ул – 10 ел инде сезнең хәрәкәтнең брендыы. Быел бу фестиваль оешманың 35 еллыгына багышланды һәм үз мәйданчыкларында 25 меңнән артык башкаручыны җыйды, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Сезнең гражданлык позициягез сайлау, аңлату һәм исәп алу кампанияләре вакытында аеруча ачык чагыла. Безнең өчен бу бик мөһим һәм гыйбрәтле. Без сезгә тормыш тәҗрибәсе, зирәк киңәшләрегез, үрнәк эшләрегез өчен рәхмәтле.

Бәйрәм җыр-бию белән үрелеп барды. Сәхнәдә «Балкыш» фестивале лауреатлары чыгыш ясады. Тәбрикләүләр, бүләкләр дә күп иде. Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова да өлкәннәргә һәрчак янәшә булганнары өчен җылы сүзләрен кызганмады.

tatarstan.ru

– Без сездән үрнәк алабыз, – диде ул. – Нинди генә эшкә тотынсак та, сезсез булмый. Хатирәләсәгез, без ялгыз калган өлкәннәрне авыллар бүйлап бергә эзләгән идек. Табып, аларга социаль хезмәткәрләр беркеттек. Бүген инде бу эшләр «Демография» илкүләм проекты кысасында башкарыла. Елдан-ел өлкәннәрнең тормышы яхшыра. Сез безгә бик кирәк. Яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләү дә – сезнең өстә. Озак еллар яшәсәгез иде.

Өлкәннәр заман белән бергә атлый. Кулларында смартфон, интернет киңлекләрендә иркен «йөзәләр». Фитнеска да йөриләр, шпагат та төшәләр, җырлыйлар да. Кайберләре хәттә «Балкыш» фестивалендә әләгә алмагач, республика ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Ииштирәков янына килеп, җырлап та күрсәтә икән.

– Өлкәннәрнең тормышы уңай якка үзгәрүгә без шат. Әле эшлисе эшләр бик күп. Сезгә чоры балаларны читтә кала, – диде ул. – Безнең эшчәнлеккә югары бәя биргән өчен җитәкчеләргә рәхмәт!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 5 өлештә «гражданлыгы» сүзеннән соң «(подданлыгы)» сүзен өстәргә;

б) 6 өлештә:

2 пунктта «затлар,» сүзеннән соң «шулай ук хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган, әлеге җинаятьләрне кылган өчен хөкем ителгән затлар – хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган көннән алып биш ел үткәнчегә кадәр,» сүзләрен өстәргә;

2^1 пунктта «127^2 статьясындагы беренче өлешендә,» сүзләреннән соң «133 статьяның икенче өлешендә, 134 статьяның беренче өлешендә,» сүзләрен, «затлар» сүзеннән соң «, шулай ук хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган, әлеге җинаятьләрне кылган өчен ирегеннән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затлар» сүзләрен өстәргә;

в) 6^1 өлештә «1^1, 1^2 һәм 2^1 пунктларында» сүзләрен «1^1, 1^2, 2 һәм 2^1 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6^1 статьяда:

а) 1 өлештә «сайлаучыларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч янаганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә:

1 пунктта «сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенең тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге муниципаль сайлауларга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге муниципаль сайлауларга карата» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди сайлауларга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди сайлауларга карата» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяда:

а) 1 өлешнең өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 12 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяда:

а) 2 өлештә «Муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре, җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссияләре, территория,» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссияләре, территория,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «13 статьясының 8 өлешендә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 өлештә «13 статьясының 8 өлеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4^2 өлештә «13 статьясындагы 8 өлеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, округ комиссиясе, территория, участок комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан икедән береннән күбрәген тәшкил итә алмый. Әлеге нигезләмә аерымланган җирләрдә, торак пунктлардан ерак җирләрдә урнашкан хәрби частьлар территорияләрендә оештырылган сайлау участокларында участок комиссияләрен формалаштырганда исәпкә алынмаска мөмкин.»;

е) 8 өлештә «җирле үзидарә органнары,» сүзләрен, «, җирле үзидарә органы» сүзләрен һәм «муниципаль районның (шәһәр округының) сайлау комиссиясенеке – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан, җирлек сайлау комиссиясенеке – муниципаль район сайлау комиссиясе тарафыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 11 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең,» сүзләрен төшереп калдырырга, «сайлау комиссиясе» сүзләрен «комиссия» сүзенә алмаштырырга;

5) 12 статьяда:

а) 10 өлештә «муниципаль районнар, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округы) сайлау комиссияләренең» сүзләрен «муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эчендәге район (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округындагы) җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы территория комиссияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

б) 10^2 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны оештыручы комиссия»;

6) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 15 статьяда:

а) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрүне тәэмин итү өчен бер йә берничә махсус территория комиссиясе төзергә хокуклы.»;

8) 16 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенең вәкаләтләре бу муниципаль берәмлек чикләрендә эшләүче участок комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

б) 6^1 өлештә «Сайлаучылар» сүзе алдыннан «Вахта поселогында,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Участок комиссиясе, җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен башкарган очракта, әлеге Кодексның 108 статьясында каралган территория комиссиясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»;

9) 17 статьяда:

а) 5 һәм 6 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 20 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләренең матди (шул исәптән акчалата түләү, башка түләүләр күләме һәм төрләре) һәм социаль тәэминаты дәрәҗәсе Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләрен матди һәм социаль тәэмин итү (шул исәптән медицина, шифаханә-курорт, торак-көнкүреш, пенсия тәэминаты һәм башка төр тәэминат) буенча кирәкле чаралар күрәләр.»;

в) 21 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

10) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «гражданлыгы» сүзеннән «(подданлыгы)» сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^1 өлеш өстәргә:

«4^1. Хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы составына үзе билгеләп куелган комиссиянең, шулай ук башка комиссиянең мәнфәгатьләрен үзенә бирелгән ышанычнамә нигезендә судта яклау хокукына ия.» беlдерергә хокуклы.»;

в) 8 өлешнең 1 пунктында «чит ил гражданлыгы» сүзләрен «чит ил гражданлыгы (подданлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 өлештә «комиссия әгъзасын билгеләп куйган» сүзләрен «компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән» сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 өлештә «комиссия әгъзасын билгеләп куйган» сүзләрен «компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән» сүзләренә, «11 – 16» саннарын «11, 12, 14 – 16» саннарына алмаштырырга, «муниципаль район (шәһәр округы) сайлау комиссиясенең яңа әгъзасы – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан, җирлек сайлау комиссиясенең яңа әгъзасы – муниципаль район сайлау комиссиясе (әгәр мондый комиссия төзелмәгән булса, – территория комиссиясе) тарафыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 11 өлештә «, муниципаль берәмлекнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре тиешле» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Хәлиткеч тавыш хокукына ия Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының, әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгәннәреннән тыш, даими (штат) нигездә эшләү мөмкинлеге, шулай ук даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларына акчалата түләү, комиссиянең бу әгъзаларына башка түләүләр күләме һәм төрләре Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

з) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын билиләр. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең даими (штат) нигездә эшләүче әгъзалары дәүләт хакимияте органнарында, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында башка вазыйфалар били алмый, укыту эшчәнлегеннән, фәнни эшчәнлек һәм бүтән иҗат эшчәнлегеннән тыш, эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый. Бу чакта укыту эшчәнлеге, фәнни эшчәнлек һәм бүтән иҗат эшчәнлеге, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, чит дәүләтләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый.»;

и) 13^2 өлештә «, акцияләргә» сүзен һәм «, акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

к) 14 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары әлеге статьяның 11 һәм 12 өлешләрендә саналган затларны матди һәм социаль тәэмин итү (шул исәптән медицина, шифаханә-курорт, торак-көнкүреш, пенсия тәэминаты һәм башка төр тәэминат) буенча кирәкле чаралар күрәләр. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисен, Рәис урынбасарын, секретарен матди тәэмин итү (шул исәптән акчалата түләү, бүтән түләүләр күләме һәм төрләре) һәм социаль тәэмин итү дәрәҗәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэмин итү дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаска тиеш. Күрсәтелгән затларга акчалата түләү күләме һәм төрләре, шулай ук башка түләүләр күләме һәм төрләре Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

л) 15 өлештә «Үзләре кергән комиссиянең вәкаләтләре тәмамлануга бәйле рәвештә вәкаләтләр чоры тәмамланган, әлеге комиссиянең яңа составы әгъзалары итеп билгеләнмәгән һәм пенсия яшенә җиткән яисә тиешле вазыйфа буенча вәкаләтләр башкарган чорда хезмәткә сәләтен югалткан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга, муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып санала торган сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган, бу комиссияләрдә даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзаларына» сүзләрен «Үзләре кергән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре чоры тәмамлануга бәйле рәвештә вәкаләтләр чоры тәмамланган әлеге комиссиянең Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре дәүләт вазыйфаларын биләгән, әлеге комиссиянең яңа составы әгъзалары итеп билгеләп куелмаган һәм пенсия яшенә җиткән яисә тиешле вазыйфа буенча вәкаләтләр башкарган чорда хезмәткә сәләтен югалткан затларга» сүзләренә алмаштырырга, «, муниципаль берәмлекләр уставларында һәм җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

м) 19 өлештә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) тиешле комиссиянең, машина тарафыннан укыла торган чыганаклардагы документларны һәм материалларны да кертеп, турыдан-туры сайлауларга бәйле документлары һәм материаллары (шул исәптән сайлаучылар исемлекләре, электрон рәвештә төзелгән исемлекләрне дә кертеп, үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гаризалар биргән сайлаучылар хакындагы белешмәләр, имза кәгазьләре, кандидатларның, сайлау берләшмәләренең финанс хисаплары, бюллетеньнәр) белән танышырга һәм шушы документларның, материалларның (бюллетеньнәрдән, сайлаучылар исемлекләреннән, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәреннән дә, имза кәгазьләреннән, федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматны тәшкил итә торган мәгълүматка кертелгән башка документлардан һәм материаллардан тыш) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне раслауны таләп итәргә хокуклы;»;

түбәндәге эчтәлекле 4^1 пункт өстәргә:

«4^1) түбәнгерәк комиссиянең әлеге өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән документлары һәм материаллары белән танышырга һәм шушы документларның, материалларның (бюллетеньнәрдән, сайлаучылар исемлекләреннән, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәреннән дә, имза кәгазьләреннән, федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматны тәшкил итә торган мәгълүматка кертелгән башка документлардан һәм материаллардан тыш) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне раслауны таләп итәргә хокуклы;»;

5 пунктта «исемлекләре» сүзеннән соң «, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәре,» сүзләрен өстәргә;

11) 20 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бердәм сайлау округы күрсәткән кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә, тиешенчә кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә документларны биргән көннән алып Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган бер әгъзасын билгеләп куярга хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^1 өлеш өстәргә:

«2^1. Бер үк зат киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы итеп бер генә комиссиягә һәм бары тик бер кандидат, бер сайлау берләшмәсе тарафыннан гына билгеләп куела ала.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 һәм 2^1 өлешләре нигезендә билгеләп куелган киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуксыз була:

1) тавыш бирү йомгаклары турында, сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә төзергә;

2) тиешле комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга һәм комиссия карарларына имза салырга;

3) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

Әлеге өлешнең нигезләмәләре киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасының үзе билгеләп куелган комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан әлеге өлештә күрсәтелгән гамәлләр башкарылганда катнашуын кире кагу өчен нигез була алмый.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 3^1 өлеш өстәргә:

«3^1. Киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы әлеге Кодексның 18 статьясындагы 19 өлешенең 1 – 4, 6 пунктларында каралган сайлаулар әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасының хокукларына ия була.»;

д) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссияләр әгъзаларының вәкаләтләре чоры тиешле сайлаулар нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көндә туктатыла.»;

е) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр кандидатка аны теркәүдән, ә сайлау берләшмәсенә кандидатлар исемлеген теркәүдән баш тартылса, йә кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү бетерелсә яисә кире кагылса, йә кандидат, кандидатлар исемлеге башка сәбәпләр белән вакытыннан алда төшеп калса, мондый кандидат тарафыннан, мондый кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе тарафыннан билгеләп куелган сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре тиешенчә теркәүдән баш тартылган, теркәү бетерелгән яисә кире кагылган көннән туктатыла, әгәр теркәүдән баш тарту турындагы карар буенча судка шикаять бирелсә, теркәүдән баш тартуның законлы булуы турында суд карары үз көченә кергән көннән йә кандидат, кандидатлар исемлеге башка сәбәпләр белән төшеп калган көннән туктатыла.»;

ж) 9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

12) 21 статьяның 1 өлешендә «югарырак комиссияләр әгъзалары» сүзләрен «югарырак комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары» сүзләренә алмаштырырга;

13) 22 статьяда:

а) 3^1 өлештә:

«Участок комиссияләренә» сүзләреннән соң «һәм территория комиссияләренә» сүзләрен, «тиешле территориаль комиссиягә,» сүзләреннән соң «округ комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйганнары – билгеләп куелган күзәтүчеләр исемлеген округ комиссиясенә,» сүзләрен өстәргә;

«муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссиягә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «комиссиягә тавыш бирү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе ике күзәтүче (берничә көн дәвамында тавыш бирү турында әлеге Кодексның 75^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе ике күзәтүче исәбеннән)» сүзләрен «участок комиссиясенә, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә тавыш бирү бинасында, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрне кабул итү, әлеге беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмә төзү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе өч күзәтүче (әлеге Кодексның 75^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган берничә көн дәвамында тавыш бирү турындагы карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе өч күзәтүче исәбеннән)» сүзләренә алмаштырырга, «Участок комиссиясенә» сүзләреннән соң «, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә» сүзләрен өстәргә;

в) 6 өлешнең 1 пунктында «исемлекләре,» сүзеннән соң «шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәре,» сүзләрен өстәргә;

14) 27 статьяда:

а) 3 өлештә беренче җөмләгә «(әлеге статьяның 3^4 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пункты бозылган очракта, сайлау участокларының исемлеге һәм аларның чикләре аларны төзү өчен каралган тәртиптә мәҗбүри төгәлләштерелергә тиеш.»;

б) 3^1 өлештә:

2 пунктта «(50гә кадәр һәм аннан да кимрәк)» сүзләрен «(100гә кадәр һәм аннан да кимрәк) йә артуы (3000нән күбрәк)» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «максималь» сүзен төшереп калдырырга;

4 пунктта «максималь» сүзен һәм «өч меңгә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «(шулай ук әлеге статьяның 3^4 өлешендә каралган очракта)» сүзләрен өстәргә;

в) 3^2 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 3^4 өлеш өстәргә:

«3^4. Казан шәһәрендә, сайлаучылар саны 500 000нән артык булган шәһәр округында, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп һәм алга таба Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, сайлаучылар саны 3000нән артык булган сайлау участоклары төзү (сайлау участоклары исемлеген һәм аларның чикләрен төгәлләштерү) рөхсәт ителә. Бу чакта сайлаучылар өчен иң уңайлы шартларны булдыру тәэмин ителергә тиеш.»;

д) 4 өлештә «(муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 5 өлештә «(муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 28 статьяда:

а) 4 өлештә «айга кимендә бер тапкыр» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм (яисә)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 8^1 өлеш өстәргә:

«8^1. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыру тәртибе, федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

16) 29 статьяда:

а) 7 өлештә «(муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 10 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 12 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 13 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле 15^1 өлеш өстәргә:

о) 28 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;
п) 29 пунктта «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларның» сүзләрен «әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затларның» сүзләренә алмаштырырга;
41) 56 статьяда:
а) 1 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә, «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «Территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә, «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен «территория комиссиясендә» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә, «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
в) 3 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
г) 4 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
д) 5 пунктның беренче абзацында «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
е) 6 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;
ж) 7 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
з) 8 пунктта «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «Территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;
и) 9 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
к) 10 пунктта «белән һәм муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән, референдум нәтиҗәләрен билгеләгәндә һәм беркетмәләрне төзегәндә шунда булган башка затларның» сүзләрен «, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән, референдум нәтиҗәләрен билгеләгәндә һәм беркетмәләрне төзегәндә шунда булган башка затларның» сүзләренә алмаштырырга;
л) 11 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
м) 12 пунктта:
«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
«үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;
н) 13 пунктта:
«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә, «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
«тиешле референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;
42) 57 статьяда:
а) 1 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;
43) 58 статьяның 3 пунктында «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе,» сүзләрен төшереп калдырырга;
44) 59 статьяда:
а) 2 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
в) 4 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
45) 61 статьяда:
а) 2 пунктта «һәм киңәш бирү тавышы» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3^{1} пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;
46) 63 статьяның беренче абзацында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.
4 статья
Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:
1) «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш);
2) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 26 маендагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);
3) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 8 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 5);
4) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 июнендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 6 (I өлеш);
5) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 7 июнендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш);
6) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 7 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш);
7) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 28 (I өлеш);
8) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш);
9) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 8 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 29 (I өлеш);
10) «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш).
5 статья
1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 – 6 пунктлары, 7 пунктның «а» пунктчасы, 9 пунктның «а» һәм «в» пунктчалары, 10 пунктның «д» – «з», «к», «л» пунктчалары, 13 пунктның «а» пунктчасындагы өченче абзацы, 14 пунктның «д» һәм «е» пунктчалары, 16 пунктның «а» – «г» пунктчалары, 25 пунктның «а» һәм «б» пунктчалары, 26, 28 пунктлар, 29 пунктның «а» пунктчасы, 33 пунктның «а» – «в» пунктчалары, «г» пунктчасының икенче абзацы, «д» – «и» пунктчалары, 36 пункт, 37 пунктның «а», «б» һәм «з» пунктчалары, 38, 43 – 60 пунктлары, 3 статьясындагы 1 – 6, 8, 9 пунктлар, 10 пунктның «а» пунктчасы, 13 пунктның «б» һәм «д» пунктчалары, 14 пункт, 16 пунктның «а» пунктчасы, 17 – 21 пунктлар, 22 пунктның «б» – «г» пунктчалары, 23 – 33 пунктлар, 34 пунктның «а» һәм «в» пунктчалары, 35 пунктның «б» һәм «д» пунктчалары, 36 пунктның «а» – «г» пунктчалары, «д» пунктчасының икенче абзацы, «е» – «к» пунктчалары, 39 пункт, 40 пунктның «а» – «в», «з», «н», «о» пунктчалары, 41 пунктның «а» – «л» пунктчалары, «м» пунктчасының икенче абзацы, «н» пунктчасының икенче абзацы, 42, 44 пунктлар, 45 пунктның «б» пунктчасы, 46 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 13 октябрь
№ 71-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышын 2022 елның 20 октябрендә 10 сәгатьтә Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1628-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәлә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышы каравына «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы» мәсьәләсен кертергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1629-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышын 2022 елның 20 октябрендә 12 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1632-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2022 елның 20 октябрендәге утыз бишенче утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләүне оештырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1630-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:
Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:
1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 340-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 343-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 331-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2^{1} статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 334-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 338-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 339-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 9 һәм 10.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 148135-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт (муниципаль) йөкләмәләре нигезендә юл эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмалар бирүнең гадиләштерелгән тәртибен билгеләү өлешендә).
11. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 173718-8 номерлы федераль закон проекты турында (магистраль газүткәргечләрдән дискриминацияләнмәгән файдалану мөмкинлеге кагыйдәләрен (тәэмин итү тәртибен) яисә аларга тоташуның билгеләнгән тәртибен (технологик тоташуны) бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1633-VI ДС

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының яңа составы төзелә башлану турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгълүмати хәбәре

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының яңа составын төзү процедурасының башлануы турында хәбәр итә.
1. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә җавап бирә торган оешма Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә гамәлдәге составтагы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына – аның яңа составына үз вәкилен кертү турында закон көченә яисә шушы оешманың уставы нигезендә тиешле вәкаләтләргә ия оешманың җитәкче коллегиаль органы карары белән рәсмиләштерелгән гариза, ә коллегиаль орган булмаганда закон көченә яисә шушы оешманың уставы нигезендә бу оешма исеменнән эшләү хокукына ия башка органның карары буенча гариза җибәрә.
Гаризага түбәндәгеләр кушып бирелә:
оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе,
оешма уставының күчермәсе һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларына кандидат күрсәтү хакындагы карарны кабул иткән органның вәкаләтләрен раслый торган башка документлар,
оешма уставы нигезендә вәкаләтле органның Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларына кандидат күрсәтү турындагы карары,
кандидат хакында белешмәләр,
кандидатның Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эшендә катнашуга язма ризалыгы,
оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат,
персональ белешмәләрне эшкәртүгә кандидатның язма ризалыгы.
2. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән гомумроссия берләшмәләренең һәм регионара иҗтимагый берләшмәләрнең структур бүлекчәләре үз кандидатуралары хакындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Президентына түбәндәге адрес буенча җибәрәләр: 420014, Казан ш., Кремль. Белешмәләр өчен телефон: (843) 567-88-92.
3. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциягә карамаган оешмалар, шул исәптән региональ иҗтимагый берләшмәләр, үз кандидатуралары хакындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге адрес буенча җибәрәләр: 420060, Казан ш., Ирек мәйданы, 1 нче йорт. Белешмәләр өчен телефон: (843) 267-64-25.
4. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр үз кандидатуралары хакындагы белешмәләрне гамәлдәге составтагы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына түбәндәге адрес буенча җибәрәләр: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7А йорт. Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 567-80-99, 567-80-94.
5. **Гаризалар 2022 елның 17 октябреннән 16 ноябренә кадәр (шул көнне кертеп) кабул ителә.**
Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешманың гаризасы үрнәге Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының рәсми сайтында (https://oprt.tatarstan.ru) урнаштырылган.

АКТҮБӘ ШАТЛЫГЫ

«ТАТНЕФТЬ» БИСТӘДӘ УНИКАЛЬ ЭКОЛОГИК ПРОЕКТНЫ ТОРМЫШКА АШЫРА

Яңалык

Кешегә бер эш калдырмаучы акыллы счетчик, кояш энергиясе белән җылытылучы өйләр, чүп-чарсыз урамнар... Безнең өчен – гаҗәп, Азнакай районының Актүбә бистәсендә яшәүчеләр өчен гадәти хәлгә әверелеп баручы күренешләр бу. «Татнефть» оешмасы бүген бистәдә әнә шундый зур экологик проектлар тормышка ашыра. Әлмәтнең нефть институтында эшләп килүче кампуста да бу максатта зур эшләр башкарыла. Нефтьчеләр тормышка ашырган уникаль проектлар белән Азнакайга күчмә утырышка җыелган Татарстан Дәүләт Советы депутатлары да танышып кайтты.

«Татнефть» ГАЖ матбугат үзәге

Кояш җылыта

«Кара алтын» бистәсе буларак танылган Актүбә бүген экологик төбәк сыйфатында да үсеп килә. «Татнефть» оешмасы ярдәме белән биредә бөтен ил күләмендә тиңнәр булмаган уникаль проект тормышка ашырыла. Актүбәне үзен-үзе җылылык, электр энергиясе белән тәэмин итәргә сәләтле, экологик яктан чиста автоном бистәгә әверелдерү күздә тотыла.

Телгә алып сөйләрлек, кулга тотып күрсәтерлек нәтиҗәләре дә бар. Тәртип бусагадан башланса, Актүбәдә әйләнә-тирә мохитне кайгырту биредәге йорт диварларыннан ук башлана. Мондагы йортларны капиталь төзекләндергәндә заманча төзелеш материаллары белән алдынгы технологияләр генә кулланыла.

Күз алдыгызга китерегез: ай буена күпме ут-су сарыф иткәнегезне сез түгел, ә автомат рәвештә счетчик үзе исәпләп бара. Ул гына да түгел, бу саннарны шул ук секундта идарәче оешмага да җибәреп куя ул. Моннан тыш шул ук счетчик хуҗасының шәхси сәхифәсенә үзенең төзек булу-булмавы турында да хәбәрләр җибәреп тора. Гаҗәп бит! Энергия ресурслары белән идарә итүнең интеллектуаль системасы кулланылган шушы йортларда яшәүчеләр өчен исә бу гадәти күренеш. Ник дигәндә, биредә йортлар әнә шундый акыллы счетчиклар белән җиһазландырылган.

Актүбәдәге йортларда «Татнефть» оешмасы керткән тагын бер яңалык күзгә ташлана. Алар кояш батареялары нигезендә эшләүче системалар ярдәмендә автоном рәвештә энергия белән тәэмин ителә башлаган. Комаров урамындагы ике йорт түбәсенә кояш батареялары урнаштырылган. Аларның берсе – 23 процент, икенчесе 47 процент энергия эшләп чыгара. Шулар хисабына мондый акыллы йортларда электр энергиясе дә 30 процентка азрак тотыла, ди белгечләр. Димәк, торак-коммуналь хезмәтләр өчен айлык түләү дә кимеячәк.

Йомычка алыштыра

Моңа кадәр Актүбәгә җылылык бистә читендә урнашкан иске генә котельныйдан килгән. Ул бик күп энергия югалтуларга китергән. Шуңа күрә «Татнефть» оешмасы бистәдә йомычкада эшләүче яңа котельный төзи башлаган. Бүген биредә композит торбалар ярдәмендә җылылык юлларын да яңарталар. Алар җылылыкны югалтмыйча саклап калырга ярдәм итәчәк. Нәтиҗәдә торак-коммуналь хуҗалык тарифлары арткан очракта да бистәдә яшәүчеләрнең айлык түләүләре артмаячак, дип ышандыралар оешмада.

Яңа котельныйда чимал итеп җирле Зәй елгасы буен басып алган Америка өрәңгесе агачларын кулланырга җыеналар. Алар махсус җиһазда йомычкага әйләнгәнче вакланачак.

«Татнефть» оешмасы инде өченче ел рәттән елга буен шушы агачлардан арындыру белән мәшгуль. Ник дигәндә, чүп агачлар рәтенә кертелгән Америка өрәңгесе басып алган җирдә башка төр үсемлекләр үсә алмый. Андый урынны бөҗәкләр дә читләп үтә. Бу исә, үз чиратында, шушы җирлектә кайбер төр хайваннар, кошларның юкка чыгуына китерә.

Проект тормышка ашырыла башлаганнан бирле Зәй буендагы 80 гектар җир шундый өрәңгедән чистартылган. Алга таба белгечләр тагын 170 гектар җирне дә чүп агачтан арындырырга җыена. Киселгәннәр урынына исә юкә, шомырт утыртылачак.

Швейцариягә ияреп

Актүбә урамнары буйлап барганда андасанда аунап яткан чүп-чарны очратырмын димә. Ник дигәндә, чүп җыюның да үз тәртибе биредә. «Татнефть» оешмасының әйләнә-тирә мохит һәм экологияне саклау идарәсенең мәгълүмат-аналитика төркеме җитәкчесе Евгений Храмов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Актүбәдәге йорт ишегалларына барлыгы 500 чүп контейнеры урнаштырылган. Шуларның 18е чүпне аерып җыю өчен билгеләнгән.

– Шул рәвешле бүген Актүбәдә чүпне аерып җыюның билгеле бер системасы булдырылды дип әйтергә була. Аның хисабына җирле каты калдыклар полигонына да «эш» азайды. Моннан тыш без пластик шешә, полиэтилен, металл, кәгазь кебек икенчел чималны төрле төр ягулык җитештерүдә куллана башладык. Проектның төп максатларына ирештек. Әмма без моның белән генә туктап калырга уйламыйбыз. Башка төр икенчел чималны да эшкәртергә җыенабыз, – ди белгеч.

✓ «Татнефть» оешмасы **2025** елга кадәр экологик программаларны тормышка ашыруга **80** миллиард сум акча бүлеп бирәчәк.
✓ Узган ел «Татнефть» тырышлыгы белән **8** миллион төп агач утыртылган.
✓ Оешма тарафыннан кулланылган энергия нәтиҗәлеге югары җиһаз бүленеп чыккан углекислый газ күләмен елына **256** мең тоннага кадәр киметергә ярдәм итә.
✓ Оешма Россиянең социаль ориентлашкан төбәкләре бишлегендә беренче урында тора. Экологик ачыклык буенча федераль рейтингта исә «Татнефть» – икенче урында.

Сүз уңаеннан, «Татнефть» оешмасының икътисади куркынычсызлык, экология һәм хезмәт саклау буенча генераль директор урынбасары Азат Хәбибрахманов сүзләренә караганда, бүген оешмада калдыкларны эшкәртү дәрәҗәсе 76 процент тәшкил итә. Чагыштыру өчен: Россия күләмендә бу күрсәткеч – 7 процент, Швейцариядә – 100, Бельгиядә – 99, Германиядә 98,5 процент.

– Яхшы күрсәткеч бу. Швейцарияне куып җитә алсак, ул безнең уртак җиңүебез булачак. Бик күп проектларыбыз нәкъ менә шуңа юнәлтелгән, – ди Азат Хәбибрахманов.

Дөньякүләм танытырлык

Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты башлыгы Азат Хамаев оешманың калдыкларны эшкәртү сәясәтен югары бәяли.

– «Татнефть» экологияне саклау юнәлешендә күптәннән саллы эш алып бара. 2000 нче елларда чишмәләрне яңарту, төзекләндерүдән башланган эш бу. Бүген алар дөньякүләм дәрәҗәдәге проектларны чынга ашыра. Азнакайда башкарылган эшләре аша алар экология мәсьәләсенә социаль яктан якын килә. Шул ук йортларны җылыту, ишагалларын төзекләндерү, агачлар утырту дисеңме. Актүбә бистәсендә тормышка ашырылган калдыкларны эшкәртү, алардан яңадан энергия табу тәҗрибәсе аеруча игътибарга лаек, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Сүз уңаеннан, калдыкларны эшкәртү эшенә бистә халкы да үз өлешен кертә. Әйтик, «Татнефть» оешмасы район һәм Актүбә мәктәбендә укучы балалар арасында ел саен пластик шешә җыеп тапшыру буенча бәйге оештыра. Иң күп пластик шешә җыйган мәктәпне – 200 мең сум, иң нык тырышкан сыйныфны – 20 мең сум, иң күп пластик шешә җыйган укучыны 10 мең сум күләмендә акчалата бүләк көтә. Шул рәвешле әйләнә-тирәлеккә сакчыл караш мәктәп бусагасыннан ук тәрбияләнә биредә.

Балачактан башлана

«Татнефть» оешмасы тарафыннан бу максатта тормышка ашырылган тагын бер зур эш игътибарга лаек. Икенче номерлы җирле мәктәптә бүген биологик лаборатория эшләп килә. Биредә укучылар сирень, каен, усак, кара бөрлегән агачларының үсентеләрен әзерли. Алга таба аларны ботаника бакчасы һәм теплицаларда үстерәләр.

Нефтьчеләр республиканың көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан тагын берничә мәктәбендә дә шундый үзенчәлекле лаборатория булдырган. Быел әлеге лабораторияләрдә укучылар 120 мең үсенте әзерләгән.

– Әйләнә-тирәлеккә карата сакчыл мөнәсәбәтне балачактан ук тәрбияләү мөһим. Мәктәпләрдә биологик лабораторияләр булдыру проекты нәкъ менә шуны максат итә дә инде. Биологияне өйрәнгәндә бала башкача фикерләргә, әйберне кулланганда чама хисен югалтмаска өйрәнә. Безнең оешма яшьләрдә әнә шундый караш тәрбияләүне күздә тота, – ди Азат Хәбибрахманов.

Кимчелек табу кыен

Мәктәп эскәмиясендә алган экологик белемкүнекмәләрнең студент чакта да кирәге чыгачак. «Татнефть» оешмасы Әлмәт нефть институты базасында махсус фәнни-тикшеренү үзәге дә оештырган. Биредә биотехнологик җитештерү эше алып барыла. Гади тел белән әйтсәк, бистәдә үскән җитен, киндердән целлюлоза, җылылык саклаучы материаллар эшләнәчәк монда.

Комитетның күчмә утырышында катнашкан Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары Ольга Манидичева «Татнефть» оешмасы тормышка ашырган проектлар арасында иң гаҗәпләндергәне дип нәкъ менә шушы үзәк эшчәнлеген атады.

– Әлмәтнең нефть институты кампусы турында күп тапкырлар ишетергә туры килде. Әмма монда шулкадәр гаҗәпләнерлек эшләр башкарыладыр дип күз алдына да китермәгән идем. «Тираж»ын арттырып таратырлык бай тәҗрибә бу, – дип уртаклашты ул хис-кичерешләре белән.

Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе башлыгы урынбасары Лилия Гайнетдинова сүзләренә караганда, «Татнефть» тикшерү органнары белән дә тыгыз элемдә тора. «Оешманың табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру өлкәсендәге тәҗрибәсе республиканың башка оешмаларына да үрнәк булырлык. «Татнефть» экологик куркынычсызлык мәсьәләсенә дә зур игътибар бирә. Шуңа күрә инспекторларга биредә ниндидер хата-кимчелекләр табу бик кыен. Шулай да камиллеккә чикләр юк», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Марсель ШӘЙДУЛЛИН,
Азнакай районы башлыгы:

Бүген «Татнефть» оешмасы Актүбә бистәсендә зур экологик проектны тормышка ашыра. Без нефтьчеләребезгә бик рәхмәтле. Биредә яңа заводлар төзелә, сәнәгать объектлары ачыла, торак йортлар, социаль объектлар төзекләндерелә, җирле халыкка эш урыннары булдырыла.

Җитәкләргә өйрәтәләр

Актерларны гына түгел, җитәкчеләрне дә укытырга кирәк. «Милли театр мәктәбе» проектына багышланган матбугат очрашуында Камал театры директоры Илфир Якупов әнә шулай диде. Өч көнлек проектның асылы һәм әһәмияте нидә?

Театр кайдан башлана? Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренчә, бүген театрларга тарихны белә торган, аралашу һәм фикерләү осталыгына ия булган көчле кадрлар кирәк.

– Россиядә театр – болай да көчле өлкәләрнең берсе. Әгәр оста актерлар гына түгел, театр дөньясындагы процессларны анализларга сәләтле булган, театраль традицияләрне, аларның тарихын яхшы белгән җитәкчеләр, оештыручылар әзерлибез икән, безгә, гомумән, тиңнәр булмаячак, – диде ул.

Министр сүзләренчә, театр әһелләрен әзерләгәндә милли театр үзенчәлекләренә игътибар аз бирелә. «Башкача әйтсәк, бүген безнең алда милли сәнгать традицияләрен, аның үзенчәлекләрен, милли тарихны яхшы белүче кадрлар әзерләү максаты тора».

Әнә шул максатны истә тотып, Казанда 14–16 октябрьдә «Милли театр мәктәбе» узачак. Бу проект Россиянең Милли драма театры (Александрия театры) һәм Милли театрлар ассоциациясе тәкъдиме белән һәм Россия халыкларының мәдәни мирасы елы кысасында оештырыла.

Милли драма театры директоры Сергей Емельянов фикеренчә, без театр идарәчеләре турында аз сөйләшәбез.

– Бүгенге театрның яңа юнәлешләре, сәнгать әһелләре, актерлар, милли драматургия проблемалары турында сөйләшкән чакта бу процесслар белән идарә итүчеләрне онытып җибәрәбез. Аларга игътибар аз бирелә. Әлеге проект бу мәсьәләне хәл итәр дип ышанабыз, – диде ул матбугат очрашуында.

Бу фикерләр белән Камал театры директоры Илфир Якупов та килеште.

– Без әледән-әле актерларыбызны, режиссерларыбызны укытабыз, аларны үстерергә кирәк, дибез. Ләкин аларның иҗат җимешләрен тамашачыга тиешле дәрәҗәдә тәкъдим итүчеләр – театр җитәкчеләре, PR белгечләр, маркетинг хезмәткәрләре, баш администраторлар да бар бит әле. Мондый проектларның әһәмияте зур дип уйлыйм. Белемнең чиге юк, – диде ул.

Шулай итеп, «Милли театр мәктәбе»ндә җәмгысы 50ләп кеше белем алачак. Бу Казан театрлары хезмәткәрләре генә түгел. «Укучы»лар бөтен республикадан җыелачак. Нәтиҗәдә алар Санкт-Петербург Дәүләт университеты имзалаган документ алачак.

«Милли театр мәктәбе»нең беренчесе Дагыстанда узган. Чираттагы проектлар Бурятия, Башкортстан, Мари Иле, Коми республикаларында, Сахалин өлкәсе һәм Камчатка краенда үткәреләчәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

МИЛЛИ ГЕРОЙЛАРНЫ БЕЛЕП ҮССЕННӘР!

Әнә шундый максат белән Татарстан китап нәшрияты белгечләре күренекле чуаш, мари, удмурт, мордва язучылары һәм шагыйрьләре сурәтләнгән 980 данә мәгълүмати плакат чыгарган. Алар республика мәктәпләренә таратылачак.

Һәр плакатка күренекле шәхеснең портреты, аның турында кыскача мәгълүмат (яшәгән еллары, эшчәнлек төре, яулаган дәрәҗәләре һәм казанышлары) урнаштырылган. Әлеге проект Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә гамәлгә ашырылган. Татарстан мәктәпләрендә барлыгы 98 кабинетны комплектлау күздә тотыла. Бер комплект исә 10 тематик плакаттан тора.

– Совет чорында колхозчылар, нефтьчеләрнең тормышын тасвирлаган плакатлар булган. Безнең нәшриятта шагыйрьләр һәм язучылар белән дә эшләгәннәр. Тик бүгенгеләренең сыйфаты элеккеләре белән чагыштырырлык та түгел. Плакатларны матур төсләр, зәвыклы заманча дизайн белән баланың игътибарын җәлеп итәрлек итеп эшләргә тырыштык. Безнең мондый тәҗрибә дә бар. Габдулла Тукай, Шәүкәт Галиев, Муса Җәлил кебек татар әдәбияты классиклары сурәтләнгән матур, төсле плакатларны 2020 елда беренче тапкыр балалар бакчаларына тараттык. Анда кечкенәдән үк бакчаларда өйрәнелә торган кызыклы һәм җиңел дүртьюллыклар урын алды, – диде Татарстан китап нәшриятының генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Илдар Сәгъдәтшин җәй дәвамында Татарстан мәктәпләренә татар әдипләре төшерелгән 21 меңнән артык плакат таратылганын әйтте.

– Гадәттә химия кабинетында Менделеев, рус әдәбияты кабинетында Пушкин, Толстой сурәтләре тора. Ә менә татар шәхесләре, күренекле әдипләребезнең сурәтләре, кызганычка, онытылып бара. Шушы эшне җайга салу өчен Президентыбыз каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән мәктәпләр өчен плакатлар эшләргә булдык. Һәр мәктәпкә 15әр плакат таратылды. Бу эшкә игътибар бирүләре өчен комиссиягә бик зур рәхмәт, – диде ул.

Илдар Сәгъдәтшин сүзләренчә, шагыйрьләр һәм язучылар гына түгел, киләчәктә үзебезнең күренекле медик, химик, физик, биологлар белән дә плакатлар эшләнәчәк.

– Эшнең күләме шактый зур. Әлеге матур бүләкләр балаларның күңеленә хуш килер дип өметләнәбез. Үз халыкларының, милләтләренең геройларын белеп үссеннәр, – ди генераль директор.

Татарстан китап нәшрияты директоры әйтүенчә, республикада эшләп килгән чуаш, мари, удмурт, мордва мәктәпләренә үз милләтендәге шәхесләр төшерелгән 1 меңгә якын плакат бу атнада таратылачак.

Ләйсән САФИНА

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ «ТНВ»ДА

Галстукта хикмәт

«ТНВ»да иртәнге эфирны алып баручы Ландыш Хөсәенова белән кызык хәл килеп чыккан. Балалар бакчасы эшләмәгәч, кызы Таңсылуны эшкә алып килгән ул. Туры эфир. Алып баручылар бөтен дөньяга хәерле иртә телиләр, иртәнге кәефне күтәрмәкче булалар. Ә Таңсылу бу мәлдә өстәл астына кереп утырган. Ландыш Хөсәенова белән алып баручының күзләре түгәрәкләнеп куя берзаман. Ландыш ни уйларга да белми, әмма сөйләвен дәвам иттерә. Баксаң, өстәл астына качкан Таңсылу алып баручының галстугын тартып утыра икән. Реклама башланганчы ничек тә түзгәннәр, ә аннары шаркылдап көлгәннәр инде.

Күгәрченнән сәлам

«Сиңа миннән сәлам» тапшыруын яздырганда, студиягә күгәрчен очып керә. Кыш була бу, җылы эзләп кергән, күрәсең. Әй оча бу арлы-бирле! Студия кунагы – Гөлдания Хәйруллина. Алар кунак кошны күрмәмешкә салыша, сер бирмиләр. Әлеге дә баягы рекламага бүленү коткара. Күрәсезме, Якубович таныткан «рекламная пауза» ничек коткара алып баручыларны? Эфирдан бүленгән арада «ТНВ»ның оператор егетләре күгәрчен куалый башлый. Ярый әле тотып алып, урамга чыгаралар. Гөлдания ханым белән әңгәмә күгәрченсез генә дәвам итә.

«Гаилә җимерүче» хат

Тапшыруга дөньяның төрле почмакларыннан котлау хатлары килә. Франция, Япония, Италия, Владивосток, Казахстан, Кыргызстан... Беркөнне мәхәббәт хаты килеп төшә. «Яшьли сөйгән ярым Фәләнова Фәлән Фәлән кызы фәләненче елда мине армиядән көтмәде, кайтуыма башкага кияүгә чыгып куйган иде, ә мин аны һаман яратам, мәхәббәтем көннән-көн арта. Шуны гына әйтәсем килгән иде», – дип язылган. Мөхәррир Алсу Әсхәдуллина аптырап кала. Нишләргә? Акчасы түләнгән, хат кабул ителгән, укымый булмый. Ә кеше гаиләсен җимерсәк? Хат юллаучыга шалтыраталар. «Бар да яхшы. Без инде бергә. Хәләл җефетемә сюрприз ясыйсым килде, борчылмагыз», – дигән абзый. Аның сүзләренә ышанып, хатны Аллага тапшырып укыйлар. Дәгъва белдерүче булмый. Хат авторы, дөрестән дә, яшьли сөйгән яры белән олыгайган көнендә кавышып, аңа сюрприз ясагандыр, дип ышанып калыйк.

Шундый исем буламыни?

Хатлар дигәннән, беркөнне юбилярның исемен Әкәлетдин дип язган хат килеп төшә. Кагыйдә буенча, хатта ничек язылган, шулай укылырга тиеш. Тик «ТНВ» кызларының күңелләрендә шик уяна. Әкәлетдин? Кит, шундый исем буламыни? Хат азагында күрсәтелгән номер буенча шалтыраталар – алучы юк. Тапшыру көне килеп җитә. Һаман трубканы алмыйлар. Эфир башлана. Сәер хатны азаккарак калдырып, телефонны алуларына өметләнәләр. Ниһаять, җавап бар! Әкмәлетдин икән ул! «М» хәрефе төшеп калган. Якыннары мондый хата җибәргәннәренә үзләре дә аптыраганнар. Шулай да, юбилеегыз котлы булсын, Әкәлетдин абзый! Гафу итегез, Әкмәлетдин абзый!

Канәгатьләндерелмәгәнлегегездән

Татарча иң озын сүзне таптык!

Халык һәм холык

Үземнең холкым турында мин нәрсә әйтә алам: берсе мине ташлап китте, икенчесе өйләнергә җыена.

* * *

– Син әз генә булса да нормальный кеше була аласыңмы?
– Сиңа кайчанга кирәк?

* * *

Кешеләр алар китап кебек. Шул бер үк хәрефләр, әмма эчтәлекләре төрле.

* * *

Минем холкымнан да начаррак тагын нәрсә бар дип уйласам, минем үз-үземне тотышым бар икән бит әле!

* * *

Балаларда иң яратканым шул: аларның минеке булмаулары.

* * *

Олыгайгач, шунысы күңелсез: син кич эштә утырасың, ә әти-әниең сине өйгә алып кайтып китми.

* * *

Без булмаган җирдә һәрвакыт яхшы, диләр. Әмма без ул тарафка инде билет алдык, тиздән кузгалабыз.

Мәһабәт мәхәббәт

– Син – әйбәт кыз үзең, әмма кирәгеннән артык психолог.

– Без тагын күрешәчәкбезме?
– Соң, конкрет әйттем бит инде мин сиңа «карарбыз» дип!

30 яшькә кадәр үзеңне олырак күрсәтергә тырышасың, ә 30дан соң – яшьрәк.

– Синең хыянәтләреңә түзәргә башка көчем калмады!
– Алай димә, син – бик көчле хатын.

– Кызганыч, бүген күрешә алмаячакбыз.
– Нигә?
– Әле уйлап тапмадым.

Менюда мәхәббәт беткәч, табын яныннан кубарга кирәкме?

Хатыны ирenә:
– Компьютерың синең өчен миннән дә кыйммәтлерәк, шулай бит?
– Долларны ничә сумнан исәпләгәндә?

Кызганыч, ул да егетен ташлады, ниһаять.

Урамда берәр гаилә талашканда, алдагы серияләрнең кыскача эчтәлеген беләсе килә.

Ирләр белән бәхәсләшү – мәгънәсез эш, чөнки алар беркайчан да хаклы булмый.

– Мин синнән китәм.
– Ник?
– Чөнки син һәр нәрсә белән бик җиңел ризалашасың.
– Ә, ярар алайса.

Эш һәм ял

Көн саен «Мерседес» белән эшкә барганчы, көн саен велосипед белән су коенырга барыр идем мин.

~ ~ ~

– Зиннур Илдарович, хәерле көн! Сезнең проект әлегә әзер түгел. Сүз уңаеннан, сезгә ташкабак кирәк түгелме?

~ ~ ~

Кешене эшкә алганда, компания үзен «зур гаилә» дип атарга ярата. Әмма проблемалы гаилә икәнен әйтеп бетерми.

~ ~ ~

Югары уку йортын тәмамлаганнан соң, синең алда бик күп юллар ачыла, себереп бетермәслек!

~ ~ ~

Кризис ул – шундый кызыклы вакыт. Менә ул бетәр дә яхшы яши башлармын, дип уйлыйсың. Ә ул бетә дә, син нәкъ шул вакытта яхшы яшәгәнеңне аңлыйсың.

~ ~ ~

«Үзеңне өйдәге сыман хис ит» дигән сүзне ишеткәч, ничек чишенә башлаудан тыелырга?

~ ~ ~

Йорт-җиреңне сирәгрәк җыештырган саен, аның нәтиҗәсе яхшырак күренә.

~ ~ ~

Ял көнне теләсә нәрсә эшләргә мөмкин, әмма берни эшлисе килми.

Совет чоры кызыклары

Иң мөһиме – дөреслек

Язгы чәчү, урып-җыю чорында колхозларга КПСС райкомыннан вәкилләр килә иде. Эшнең барышы белән кызыксыналар. Яңарак кына эшли башлаган егеткә дә колхозга бару бурычы йөкләнә, әмма бару өчен бернинди техника да юк. Егет колхоз рәисе белән элемтәгә керә, тик уңай җавап таба алмый. 10–12 километр араны җәяүләп барып җитә һәм хуҗалык җитәкчесеннән ничек тә үч алмакчы була. Җае да чыгып тора: колхоз рәисе белән амбар мөдире җайлы гына урында чәкешеп торалар түгелме соң? Егет шундук райкомга хәбәр сала. Беренче секретарь тиз арада бюро җыярга әмер бирә, нинди хәл бу, башкаларга сабак булсын, янәсе. Бюрода егет иң әүвәл хәлне аңлата: «Кулларында бер ярты, урындыкларында помидор иде, – ди, – үз күзләрем белән күрдем!»

– Их, энекәш, күреп җиткермәгәнсең шул, – дип аклана җитәкче, – кулда ярты түгел, «чүлли» генә иде (безнең якта 250 граммлы шешәне шулай атыйлар), аннан, помидор түгел, кыярдан авыз иттек. Шулай булгач, егетнең сүзе дөреслеккә туры киләме? Чеп-чи ялган!

Тик беренче секретарьның, бюро әгъзаларының талканы коры: колхоз председателенә шелтә чәпиләр. Теге исә барыбер үз фикерендә кала: «Ни генә булса да, иң мөһиме – дөреслек!»

«Тәби»гә дә, «Бәти»гә дә рәхмәт

Көннәрдән бер көнне районыбызның бик алдынгы хуҗалыгына КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табеев киләчәге мәгълүм була. Ул үтәсе юл буенда бер әбинең коймасы җимерелеп беткән икән. Тиз арада эшкә керешәләр һәм койма күз явыңны алырлык итеп төзәтелә.

Бер-ике ел үткәч, Югары Совет рәисе Салих Батыевның да шул ук хуҗалыкка киләчәге билгеле була. Теге әбинең коймасы менә дигән, лапас түбәсе исә җимерелә башлаган, аны да тиз арада рәткә китергәннәр. «Тәби»гә дә рәхмәт, «Бәти»гә дә рәхмәт, дип сөенгән әби.

М. БӘДРӘШИТОВ.
Актаныш районы

ТУФТАЛОГИЯ

- 50 килолы герне күтәрү – пүчтәк ул! Син менә минем кәефемне күтәреп кара.
- Яшь барган саен, күзләрем начар күрә башлады, шуңа күрә кияүгә чыгарга бернинди сәбәп тә күрмим.
- Акчаны акыл белән тоту өчен нибары ике нәрсә кирәк.
- Мин иронияга каршы түгел, әмма «хәерле иртә» сүзендә ул чамадан тыш артык.
- Минем тормышым ул – «сакланганны саклармын дигән» һәм «чәнчелеп китсен» арасында баланс тотарга тырышу.
- Урамда үзегезне кинәт начар хис итсәгез, шунысын уйлагыз: моңарчы сез үзегезне яхшы хис итә идегезме соң?
- Минем сүз байлыгым бик зур, әмма сүзләрне бер җөмләгә тезә башласам, әллә нәрсә чыга килеп инде вот.
- «Кирәкми, бик зур рәхмәт!» – дип әйтәм мин «Пычагымамы инде бу миңа!» – дип уйлап куйган очракларда.

Мач әйткән!

Андрей МИРОНОВ, театр һәм кино актеры

Аттан егылыр өчен башта аның өстенә менәргә кирәк.

КЫЗЫМ, СИҢА ӘЙТӘМ

Кияүгә яшьтән үк чыгарга кирәк. Яхшы ир эләксә – бәхетле хатын, начар ир эләксә – психолог булырсың.

* * *

Туй ул – бик күңелле нәрсә. Кеше туе булганда.

* * *

Бу хатыннарны аңламассың. Башта, кияүгә чыгам дип, әниләрен куркыталар. Аннары әнигә чыгып китәм дип – ирләрен.

* * *

Әгәр дә чын-чынлап яратасыз икән, берәүнең дә сүзен тыңламагыз. Бөтен җаныгызны биреп яратыгыз һәм сөйгәнегезгә ышаныгыз. Әмма фатирны үз исемегезгә яздырыгыз.

* * *

Киңәшем шул: киңәшләргә колак салмагыз.

Фотофакт

Бу – 1995 елгы фотосурәт. Әлеге артистларны илебездә белмәгән кеше юктыр. Бу аларның бергә төшкән иң соңгы фотолары. Юрий Никулин – 1997 елда, Евгений Моргунов – 1999 елда, Георгий Вицин 2001 елда арабыздан китте. Әмма алар уйнаган бик күп кинофильмнар калды. Һәм без, аларны кабат-кабат карап, юаныч табабыз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 352

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+